
Лэмберэ районы депутатлар советынын чираттагы 22 нче сессиясенен кинэйтелгэн утырышы vткэн. Кон тэртибендэге топ мэсьэлэ - 2023 елда территориянен социаль-икътисади vсешенэ йомгак ясау һэм алдагы чорга бурычлар кую иде. Сессия эшендэ Мордовия Республикасы Главасы Артём Алексеевич Здунов катнашкан.
2023 елдагы эш нэтижэлэре һэм 2024 елга бурычлар турында топ доклад белэн Лэмберэ районы житэкчесе Юрий Иванович Голов чыгыш ясаган. Ул тvбэндэге эшлэр турында ишеттергэн. Юллар елына 17 км (якынча 550 млн сум) тозv һэм ремонтлау планлаштырыла. Президентыбызнын йоклэмэсен vтэп, быел 816 йортка газ керткэннэр.
Тозеклэндерv – «Заманча шэһэр мохитен формалаштыру» Федераль проекты буенча Лэмберэнен Ленин урамындагы паркны тэртипкэ китерэчэклэр, ишегалды тер-риториялэрен тозеклэндерvне дэвам итэчэклэр. Шулай ук Атемар авылында су алу узелы һэм су чистарту станциясе тозv мэсьэлэлэре хэл ителэчэклэр. Махсус объект – Атемарда калдыкларны эшкэртv буенча муниципаль-ара комплекс һэм полигон тозv - 3 млрд.сумнан артык инвестиция һэм 200дэн артык яна эш урыны булыр.
Федераль программа буенча – Пензятка һэм Первомайский мэктэплэрен, планда – 2 нче Лэмберэ урта гомуми белем бирv мэктэбен, Атемар мэктэбен һэм 4 балалар бакчасын капиталь ремонтлауны дэвам итэчэклэр. Берсеневка мэктэбендэ спорт залын ремонтлау, Кривозерье һэм Саловка мэктэплэре очен компьютер жиһазлары сатып алу планлаштырылган.
Килэсе елда Лэмберэ поликлиникасын капиталь ремонтлауны тэмамларга исэп, ФАПларны алыштыру эшен дэвам итэчэклэр. Бу – район халкынын наказлары.
Сессия нэтижэлэрен йомгаклап, Мордовия Республикасы башлыгы А.А.Здунов Лэмберэ районынын югары потенциалын билгелэп vткэн.